**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15.02.2023** **Чирмешән авылы** **№ 35**

**Торак урыны мәйданының исәп нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәпкә алу максатында торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына исәпләнгән торак урынның гомуми мәйданының 18 квадрат метрдан артмаган күләмендә билгеләнә торган торак урын мәйданының исәп-хисап нормасын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга исәпләнгән торак урынының гомуми мәйданының 18 кв.метры күләмендә билгеләргә.
3. Торак бинаның гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданының исәп нормасын һәм торак урыны бирү нормасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2007 елның 25 июлендәге №186 карары үз көчен югалткан дип таныргa.
5. Әлеге карарны Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.М.Җамалетдинов